МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.12.2016 Казан ш. № 385

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” Федераль законга һәм “Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында” Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында” 2016 елның 3 июлендәге 277-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында б о е р а м:

1. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертеләчәк түбәндә теркәлгән үзгәрешләрне расларга (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2015 елның 19 мартынлагы 135нче, 2015 елның 28 июлендәге 346нчы, 2016 елның 2 июнендәге 177нче боерыклары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), (алга таба – Үзгәрешләр, Административ регламент).

2. Боерыкның, түбәндәгеләрдән кала, рәсми рәвештә бастырылган көннән үз көченә керүен билгеләргә:

Үзгәрешләрнең 2017 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган уникенче, унөченче, егерме алтынчы – утыз бишенче, кырык тугызынчы, илле сигезенче, җитмеш беренче – җитмеш алтынчы, сиксәненче, сиксән беренче абзацларыннан кала.

3. Дәүләт мәгълүмат ресурслары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара эш итү бүлегенә (Сәгыйтов И.С) әлеге боерыкның Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы сайтына урнаштырылуын тәэмин итәргә.

4. Әлеге боерыкның үтәлешенә контрольлек итүне Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары А.Д.Шәмсиевкә йөкләргә.

Министр А.А.Здунов

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгы боерыгы
белән расланган
06.12.2016 № 385

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының 2013 елның 26 мартындагы 96нчы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсендә лицензия контролен гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәвенең административ регламентына кертеләчәк үзгәрешләр

Административ регламентның 1 бүлегендә:

1.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.2. Дәүләт функциясен үтәүче булып Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы тора (алга таба – Министрлык).

Дәүләт функциясен турыдан-туры үтәүче булып Министрлыкның Административ реформа мәсьәләләре идарәсенең лицензияләү бүлеге тора (алга таба – Бүлек).

Дәүләт функциясе Татарстан Республикасы икътисад министры (алга таба – министр), (Татарстан Республикасы икътисад министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) тарафыннан имзаланган боерык белән тикшерүләрне үткәрүгә вәкаләт бирелгән Министрлыкның вазыйфаи затлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан башкарыла.

Тикшерүләрнең бердәм реестрына «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында” 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 маддәсенә һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында” 2015 елның 28 апрелендәге 415нче карарына (алга таба – РФ Хөкүмәтенең

415нче карары) ярашлы рәвештә тиешле мәгълүматны кертү Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан башкарыла.

Министрлык тарафыннан дәүләт функциясен үтәү түбәндәгеләр белән үзара эш итү аша башкарыла:

- планнан тыш күчмә тикшерүләрне үтәүне килештерү, планлы тикшерүләрне үткәрү планын килештерү сораулары буенча прокуратура органнары белән;

- мөрәҗәгатьләре буенча юридик затлар, гражданнар белән;

- экспертлар – шәхси эшкуар булмаган, кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату сферасында дәүләт лицензия контроле өлкәсендә техник экспертиза үткәрү тәҗрибәсе булган, махсус белемнәргә ия, контроль буенча чараларга җәлеп итү максатларында билгеләнгән тәртиптә Министрлыкта аттестацияләнгән гражданнар белән;

- эксперт оешмалары – аккредитация турында Россия Федерациясе законнарына ярашлы рәвештә аккредитациянең милли системасында аккредитция үткән һәм Министрлык тарафыннан контроль буенча чараларга җәлеп ителә торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән.»;

1.6.3 пунктның  11 пунктчасын түбәндәге редакциядә бирергә:

11) лицензиягә дәгъва кылучыдан, лицензиаттан тикшерүне башлау датасына кадәр документлар, мәгълүматлар тапшыруын таләп итәргә. Министрлыкта тикшерүне үткәрү турында боерык кабул ителгәннән соң, ведомствоара мәгълүмати эш итү кысаларында кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматларны соратып алырга хокуклы.»;

1.8 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

1.8. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре

Дәүләт функциясен үтәүнең соңгы нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату өлкәсенә караган законнардагы лицензия таләпләренең үтәлешен тикшерү буенча РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141нче боерыгы белән расланган формада тутырылган акт (алга таба – тикшерү акты), 2 нөсхәдә;

2) 294-ФЗ номерлы Федераль законның 13.3 маддәсенә һәм РФ Хөкүмәтенең 415нче карарына ярашлы рәвештә тикшерүләрнең бердәм реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

3) тикшерүләрне исәпкә алу журналы булганда, үткәрелгән күчмә тикшерү турында әлеге журналга теркәлгән язма (тикшерүләрне исәпкә алу журналының типлаштырылган формасы РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141нче боерыгы белән расланган);

лицензия таләпләрен бозу ачыкланганда:

4) министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган, 294-ФЗ номерлы Федераль законның 17 маддәсе 1 пункты 1 пунктчасында каралган таләпләрне исәпкә алып төзелгән, хилафлыкларны юкка чыгару сроклары күрсәтелеп, ачыкланган лицензия таләпләрен бозуларның юкка чыгарылуы һәм (яисә) тиешле чаралар үткәрелүе хакында боерык (алга таба – боерык) (әлеге Регламентка теркәлгән 1нче Кушымта);

5) ачыкланган хилафлыкларны юкка чыгаруны контрольдә тоту, аларны кисәтү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), әйләнә-тирә мохиткә, үсемлекләргә, хайваннарга, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә ихтимал булган зарар китерүне булдырмый калу, дәүләт куркынычсызлыгын тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрнең барлыкка килүен кисәтү буенча чаралар, һәм шулай ук ачыкланган хилафлыкларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрү.

Дәүләт функциясен үтәү өчен Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан килгән мөрәҗәгать яисә гариза, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – гариза бирүче) алынган мәгълүмат нигез булып торган очракларда, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча гариза бирүчегә 59-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап юллана.

Контроль буенча чаралар үткәргәндә, лицензиатның контроль чарасын үткәрү объекты булган эшчәнлеге закон таләпләрен бозу белән бәйле булып, аларны ачыклау, булдырмый калу һәм кисәтү сораулары Министрлык компетенциясенә

карамаган очракларда, Министрлык әлеге хокук бозулар турындагы мәгълүматны (хәбәрне) Россия Федерациясе яисә Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең вәкаләтле органнарына юлларга тиеш.»;

Административ регламентның 2 бүлегендә:

2.1.5 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.1.5. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан мәҗбүри таләпләрнең бозылуын кисәтү, мәҗбүри таләпләрнең бозылуына этәргеч бирә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында, Министрлык үзе тарафыннан ел саен расланаучы хокук бозуларны профилактикалау программаларына ярашлы рәвештә хокук бозуларны профилактиикалау чараларын гамәлгә ашыра.

Министрлыкның рәсми сайтында, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләр порталында, Министрлык бинасында эленгән мәгълүмат такталарында Бүлек белгечләре тарафыннан үзгәрешләр кертелү ешлыгына бәйле рәвештә түбәндәге мәгълүмат урнаштырыла һәм яңартылып тора:

- дәүләт функциясен үтәү тәртибенә кагылышлы Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарының төп нигезләмәләре турында;

- үтәлешен бәяләү лицензион контроль предметы булган мәҗбүри таләпләр кергән норматив-хокукый актларның яисә аларның аерым өлешләренең исемлеге, һәм шулай ук әлеге норматив-хокукый актларның текстлары;

- Министрлык боерыгы белән расланган хокук бозуларны профилактикалау программасы;

- дәүләт контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумләштерү, шул исәптән мондый хилафлыкларны булдырмый калу максатларында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга карата киңәшләр белән бергә, мәҗбүри таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп;

- лицензия таләпләрен үтәү сораулары буенча лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар өчен, шул исәптән лицензия таләпләрен үтәү буенча белешмәлекләрне эшләү һәм бастыру, семинар һәм конференцияләр уздыру, массакүләм мәгълүмат чараларында аңлату эшләре алып бару аша һәм башка ысуллар белән;

- лицензия таләпләре үзгәртелгән очракта, мәҗбүри таләпләрне билгели торган яңа норматив-хокукый актларның эчтәлеге, гамәлдәге актларга кертелгән үзгәрешләр, аларның үз көченә керү вакыты һәм тәртибе турында аңлатмалар, һәм шулай ук мәҗбүри таләпләрне кертүгә һәм аларның үтәлешен тәэмин итүгә юнәлдерелгән оештыру, техник чаралар уздыру турында киңәшләр;

- лицензия контролен гамәлгә ашыру тәҗрибәсен гомумиләштерү (елына бер мәртәбәдән дә ким түгел), шул исәптән мондый хилафлыкларны булдырмый калу максатларында лицензиягә дәгъва кылучылар, лицензиатлар тарафыннан күрелергә тиешле чараларга карата киңәшләр белән бергә, мәҗбүри таләпләрне бозуның иң еш очрый торган очракларын күрсәтеп;

- әлеге Регламент;

- Министрлык боерыгы белән расланган планлы тикшерүләрне уздыруның еллык планы (алга таба – План);

- Министрлыкның урнашкан урыны, эш графигы, телефон һәм факс номерлары, электрон почтасы адресы;

- дәүләт функциясен үтәү барышында гамәлгә ашырыла (кабул ителә) торган гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм карарларга карата дәгъва белдерү тәртибе;

- дәүләт функциясен үтәгәндә гамәлләрнең эзлеклелеген чагылдыра торган блок-схема.»;

2.3 бүлекчәсен түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.3. Дәүләт функциясен үтәү сроклары һәм ешлыгы

Һәр тикшерүне (планлы, планнан тыш, күчмә, документар) үткәрү срогы егерме эш көненнән дә озаграк була алмый.

Бер кече эшкуарлык субъектына карата планлы күчмә тикшерүләрне үткәрүнең гомуми срогы бер елга кече предприятие өчен - илле сәгатьтән, микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән дә артык була алмый.

Министрлыкның күчмә планлы тикшерү үткәрә торган вазыйфаи затларының дәлилле тәкъдимнәре нигезендә махсус экспертизалар һәм тикшеренүләр, сынаулар, катлаулы һәм (яисә) озакка сузылган эзләнүләрне уздыруның кирәклегенә бәйле аерым очракларда күчмә планлы тикшерүне үткәрү срогы министр тарафыннан озынайтыла ала, ләкин егерме эш көненнән дә артыгракка түгел, кече

предприятиеләргә карата - илле сәгатьтән дә, микропредприятиеләр өчен унбиш сәгатьтән дә артыгракка түгел.

Кече эшкуарлык субъектына карата планлы күчмә тикшерүне үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати эш итү кысаларында документлар һәм (яисә) мәгълүмат алу таләп ителгән очракта тикшерүне үткәрү министр (министр урынбасары) тарафыннан ведомствоара мәгълүмати эш итү өчен кирәкле вакытка кадәр туктатылып тора ала, ләкин ун эш көненнән дә артыгракка түгел.

Тикшерүне үткәрүне кабаттан туктату рөхсәт ителми. Тикшерүне үткәрүне туктатып тору срогының гамәлдә булу вакытында Министрлыкның әлеге тикшерүгә бәйле кече эшкуарлык субъекты территориясендә, биналарда, корылмаларда, бүлмәләрдә һәм башка объектлардагы гамәлләре туктатыла.

Үз эшчәнлеген Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә алып баручы лицензиатка карата үткәрелә торган һәр тикшерүнең (һәм документар, һәм күчмә) срогы һәр филиал, вәкиллек, юридик затның аерымланган структур подразделениесе буенча аерым билгеләнә, шул ук вакытта тикшерүне үткәрүнең гомуми вакыты алтмыш эш көненнән дә артык була алмый.

Планлы тикшерүләр өч елга бер мәртәбәдән дә ешрак үткәрелми.»;

2.4.1 пунктындагы «нигезендә эшләнелә торган» сүзләрен «һәм раслана торган» сүзләре белән тулыландырырга;

2.4.2 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«2.4.2. Планнан тыш тикшерүләрне үткәрү өчен нигезләр булып түбәндәгеләр тора:

1) тикшерү барышында ачыкланган лицензия таләпләрен бозуны юкка чыгару турында Министрлык тарафыннан алданрак бирелгән боерыкның лицензиат тарафыннан үтәлеше срогының тәмамлануы, бу очракта тикшерү предметы булып Министрлык тарафыннан бирелгән боерыкның үтәлеше генә тора ала;

2) лицензиат тарафыннан лицензия таләпләренең тупас бозуылуы фактлары турында Министрлыкка гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан килгән мөрәҗәгатьләр, гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан алынган мәгълүматлар керү;

3) Министрлык күрсәтмәсен вакытыннан алда үтәлеше фактын билгеләү максатларында Министрлык тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү турында лицензиатның үтенеч язуының булуы;

4) Министрлыкның Россия Федерациясе Президенты яисә Россия Федерациясе Хөкүмәте күрсәтмәсенә ярашлы рәвештә бастырылган боерыгының булуы;

5) лицензиягә дәгъва кылучының лицензия бирү турында яисә лицензиатның лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында гариза тапшыруы (99-ФЗ номерлы Федераль законның 13 һәм 18 маддәләрендә каралган очракларда лицензия бирүче орган тарафыннан документар тикшерүләр һәм планнан тыш күчмә тикшерүләр билгеләнгән тәртиптә прокуратура органы белән килештерүләрсез башкарыла).»;

түбәндәге эчтәлекле 2.4.3 – 2.4.10 пунктлар белән тулыландырырга:

«2.4.3. Министрлыкка мөрәҗәгать итүче затны ачыкларга мөмкинлек бирмәгән мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, һәм шулай ук әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында белешмәне үз эченә алмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез була алмыйлар. Мөрәҗәгатьтә яисә гаризада китерелгән мәгълүмат әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасына ярашлы рәвештә планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез була алганда, Министрлыкның вазыйфаи заты, үзендә мөрәҗәгатьнең яисә гаризаның авторлыгына карата нигезле шик туганда, мөрәҗәгать итүче затны билгеләү буенча чаралар күрергә тиеш. Гариза тапшыручы тарафыннан электрон формада юлланган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар идентификация һәм аутентификациянең бердәм системасында гариза бирүченең мәҗбүри рәвештә автор буларак теркәлүен күздә тота торган мәгълүмат-коммуникация технологияләре чараларын кулланып юлланган шартларда гына планнан тыш тикшерүне үткәрү өчен нигез була алалар.

2.4.4. Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген башкарганда лицензия таләпләрен тупас бозу очракларының тулы исемлеге РФ Хөкүмәтенең 1287нче карары белән расланган Кара металл, төсле металл калдыкларын җыю, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә (алга таба – Лицензияләү турында нигезләмә) тарафыннан

билгеләнә. Шул ук вакытта лицензия таләпләрен тупас бозуларга үз артыннан түбәндәгеләрне китереп чыгарган хилафлыклар кертелергә мөмкин:

а) Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), әйләнә-тирә мохиткә, үсемлекләргә, хайваннарга, гражданнарның тормышына, сәламәтлегенә зарар китерү куркынычы, һәм шулай ук техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр куркынычы янау;

б) кеше корбаннары яисә гражданнарның сәламәтлегенә авыр зарар китерү, ике һәм аннан да күбрәк граждан сәламәтлегенә уртача авырлыктагы зарар китерү, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирасы объектларына (тарих һәм мәдәният һәйкәлләренә), әйләнә-тирә мохиткә, үсемлекләргә, хайваннарга зарар китерү, техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү, гражданнарның хокукларына, законлы мәнфәгатьләренә, ил оборонасына һәм дәүләт куркынычсызлыгына зыян салу.

2.4.5. Әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм мәгълүматлар каралганда элегрәк кергән шундый ук мөрәҗәгатьләр, гаризалар һәм мәгълүматларны тикшерү нәтиҗәләре, һәм шулай ук әлеге лицензиатка карата элегрәк үткәрелгән контроль чаралары нәтиҗәләре исәпкә алынырга тиеш.

2.4.6. Мәҗбүри таләпләрне бозган зат турында дөрес хәбәр булмаганда, мәҗбүри таләпләрнең бозылуы яисә әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат булмаганда, Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан кергән мәгълүматка карата алдан якынча тикшерү үткәрелергә мөмкин. Алдан якынча тикшерүне үткәрү барышында гариза һәм мөрәҗәгать юллаган, мәгълүмат тапшырган затлардан өстәмә белешмә һәм мәгълүмат соратып алу (шул исәптән телдән) буенча чаралар күрелә, лицензиатның Министрлык карамагында булган документлары тикшерелә. Алдан якынча тикшерү кысаларында кергән мәгълүматка карата лицензиаттан аңлатма бирү соратыла ала, ләкин мондый аңлатмаларны һәм башка документларны бирү мәҗбүри түгел.

2.4.7. Алдан якынча тикшерүләр нәтиҗәләре буенча мәҗбүри таләпләрне бозган затлар ачыкланганда, мәҗбүри таләпләрне бозу турында яисә әлеге

Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән фактлар турында җитәрлек мәгълүмат алынганда, Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр буенча планнан тыш тикшерү үткәрүне билгеләү турында дәлилләнгән язма әзерли. Алдан якынча тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензиатны җаваплылыкка тарту чаралары күрелми.

2.4.8. Әлеге тикшерү башланганнан соң аны оештыру өчен сәбәп булган мөрәҗәгать яисә гаризаның аноним булуы, яки мөрәҗәгатькә яисә гаризага күрә торып дөрес булмаган хәбәр кертелүе ачыкланганда алдан якынча тикшерү, планнан тыш тикшерү министр (министр урынбасары) карары белән туктатыла.

2.4.9.Министрлык, гаризаларга, мөрәҗәгатьләргә күрә торып дөрес булмаган хәбәр кертелгәндә, Министрлыкның әлеге затларның гаризаларын, мөрәҗәгатьләрен карауга бәйле чыгымнарын гражданиннан, шул исәптән юридик заттан, шәхси эшкуардан кайтарту турында дәгъва белән судка мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

2.4.10. Эшчәнлекнең лицензияләнә торган төре гамәлгә ашырылу урыны буенча урнашкан прокуратура органы белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгәннән соң, әлеге Регламентның 2.4.2 пункты 2 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча лицензиатка карата планнан тыш күчмә тикшерү лицензиатка алдан ук хәбәр юлламый гына үткәрелә ала.

Министрлык тарафыннан планнан тыш күчмә тикшерү үткәрүне прокуратура органы белән килештерү турында гаризаның типлаштырылган формасы Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 нче боерыгы белән расланган.»;

Административ регламентның 5 бүлегендә:

5.1 бүлекчәсендә:

5.1.5 пунктында:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.1.5. Лицензиатка планлы күчмә тикшерү үткәрелүе турында хәбәр җаваплы башкаручы тарафыннан планлы күчмә тикшерү турында боерыкның күчермәсен почта элемтәсе аша иясенә тапшырылу турында белдерү кәгазе беркетелгән заказлы хат һәм (яисә) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ шәкелендә лицензиатның электрон адресына (әгәр мондый адрес юридик

затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында теркәлгән  яисә Министрлыкка лицензиат тарафыннан тапшырылган булса) юллау аша яисә башка ысул белән җиткерелә.»;

өченче абзацта  «өч эш көне дәвамында» сүзләрен «өч эш көнендә» сүзләре белән алыштырырга;

5.1.7 пунктын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Җитәкченең, башка вазыйфаи затның яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиленең булмавына бәйле, яисә җитәкченең,  башка вазыйфаи затның яисә лицензиатның вәкаләтле вәкиленең тикшерүне үткәрү мөмкинлеген юкка чыгаруга китергән башка гамәлләренә (гамәлләр кылмавына) бәйле рәвештә планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү мөмкин булмаган очракларда, Министрлыкның вазыйфаи заты, тикшерүне үткәрмәүгә китергән сәбәпләрне күрсәтеп, тиешле тикшерүне үткәреп булмавы турында акт төзи. Бу очракта Министрлык тиешле тикшерүне үткәрү мөмкин булмавы турында акт төзелгән көннән башлап өч ай эчендә, планлы тикшерүләрнең еллык планына планлы тикшерүне үткәрүне кертмичә һәм лицензиатка алдан ук хәбәр салмыйча гына, мондый лицензиатка карата планлы һәм планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында карар кабул итәргә хокуклы.»;

5.2.6 пунктның 3 абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«Әлеге Регламентның 2.4.2. пунктының 5 пунктчасында билгеләнгән нигезләр буенча планнын тыш документар тикшерүне үткәргәндә җаваплы башкаручы шулай ук лицензия контролен үткәрү максатлары өчен кирәк булган Күчемсез милеккә һәм алар белән сделкаларга хокукларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтәләрне (күчемсез милек объектына теркәлгән хокуклар турында гомумачык мәгълүмат кертелгән), күчемсез милек объектлары турында кадастр өземтәләрен, күчемсез милек объектларының кадастр паспортларын, Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр, Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр алу өчен дәүләт хакимиятенең башка органнарына, дәүләт мәгълүмат системасына ведомствоара электрон эш итү системасы ярдәмендә электрон формада запрослар юллый.»;

5.2 бүлекчәсенең 5.2.7 пунктында:

беренче абзацта «, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә» сүзләрен алып ташларга;

дүртенче абзацны «Күчмә тикшерүне үткәргәндә юридик заттан, шәхси эшкуардан документар тикшерү барышында алар тарафыннан тапшырылган документларны һәм (яисә) мәгълүматны тапшыруны таләп итү тыела.» сүзләре белән тулыландырырга;

бишенче абзацта «5.3 бүлегенә ярашлы рәвештә» сүзләрен «5.3 бүлекчәсенә ярашлы рәвештә сүзләре белән алыштырырга»;

5.3 бүлекчәсе 5.3.6 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

«5.3.6. Вазыйфаи зат планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү (әлеге Регламентның 2.4.2. пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән нигезләр планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрүгә сәбәп булган очраклардан тыш) турында тикшерү үткәрергә егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча барлык мөмкин булган ысуллар белән, шул исәптән көчәйтелгән квалификацияле электрон имза куелган электрон документ шәкелендә лицензиягә дәгъва кылучының, лицензиатның электрон адресына (әгәр мондый адрес юридик затларның бердәм дәүләт реестрында, шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрында теркәлгән яисә Министрлыкка дәгъва кылучы, лицензиат тарафыннан тапшырылган булса) юллау аша лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка хәбәр итә.».